ГЛАВА САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.09.2026 с. Сарманово № 190

Гавами тыңлауларны билгеләү турында

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Зур Нөркәй авыл җирлегендә яшәүчеләрнең фикерләрен һәм мәнфәгатьләрен ачыклау һәм исәпкә алу максатларында Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясындагы 13.1 пункты һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль закон нигезендә карар бирәм:

1. 2026 елның 06 октябренә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Зур Нөркәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар уздыруны билгеләргә.
2. Гавами тыңлауларны оештыручы итеп Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы башкарма комитеты билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Зур Нөркәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең ТР, Сарман районы, Зур Нөркәй авылы, с.Рафиков ур., 32 йорт адресы буенча җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча халык алдында тыңлаулар уздырырга.
4. Сарман муниципаль районының «Зур Нөркәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, шулай ук гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелергә мөмкин: Сарман муниципаль районы, Сарман авылы, Ленин ур., 35 (эш көннәрендә - 8.00 дән 16.30 га кадәр). Чыгыш хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга заявкалар бирү срогы - 2026 елның 05 октябре.
5. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советының 2007 елның 24 мартындагы 113 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районында гавами тыңлаулар уздыру тәртибе турында нигезләмәдә билгеләнгән тәртип буенча, шәһәр төзелеше законнарында билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып, гавами тыңлаулар уздырырга.
6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә (PRAVO.TARSTAN.RU) һәм Сарман муниципаль

районының рәсми сайтында урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны МР Советының инфраструктура үсеше мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Сарман муниципаль районы
Башлыгы Ф.М. Хөснуллин